| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ<br>ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.06.2019 Алексеевск ш.т.б. № 265

**«Торак биналарны торак булмаган, торак булмаган биналарны торак биналарга күчергәндә документларны рәсмиләштерү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2008 елның 29 апрелендәге 105 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясенең Торак кодексына үзгәрешләр кертү сәбәпле

**карар бирәм:**

1. «Торак биналарны торак булмаган, торак булмаган биналарны торак биналарга күчергәндә документларны рәсмиләштерү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2008 елның 29 апрелендәге 105 нмерлы карарына үзгәрешләр кертергә:

- 1 кушымтаның 4.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә

«4.1. Әгәр торак биналардан файдаланмыйча гынакүчерелүче бинага керү мөмкинлеге булмаса,яки бу бинага мондый керү мөмкинлеген җиһазлауның техник мөмкинлеге булмаса,әгәр күчерелүче бина торак бинаның бер өлеше булса яки әлеге бинаның хуҗасы тарафыннан кулланылса, шулай ук әгәр дә күчерелүче бинага милек хокукы нинди дә булса затларның хокуклары белән чикләнә икән, торак бинаны торак булмаган бинага күчерү рөхсәт ителми. Бина торак бинадан торак булмаган бинага күчкәннән соң, бүлмәләрне файдалану юлы белән торак биналарга керү мөмкинлеге ябылырга тиеш»;

- 1 кушымтаның 5.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә

«5.1.Башкарма комитет җитәкчесе исеменә күчерү өчен нигезләр һәм аны алга таба куллану максатлары күрсәтелгән гаризалар кабул итүне Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге (алга таба – бүлек) түбәндәге документлар булганда гамәлгә ашыра:

1) бинаны күчерү турында гариза;

2) кучерелүче бинага хокук билгеләүче документлар (төп нөсхәләр яки нотариуста расланган күчермәләр);

3) күчерелүче бинаның техник тасвирламасы белән планы (әгәр күчерелүче бина торак булса, мондый бинаның техник паспорты);

4) күчерелүче бина урнашкан йортның һәр катына план;

5) күчерелүче бинаны яңадан төзү һәм (яки) үзгәртеп планлаштыру буенча билгеләнгән тәртиптә әзерләнгән һәм рәсмиләштерелгән проекты (үзгәртеп кору һәм (яки) үзгәртеп планлаштыру мондый бинаны торак яки торак булмаган бина буларак кулланууны тәэмин итү өчен кирәк булган очракта);

6) үз эченә торак бинаны торак булмаган бинага күчерүгә ризалык турында карар алганкүпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләренең гомуми җыелышы беркетмәсе;

7) күчерелүче бина янәшәсендә урнашкан һәр бина хуҗасының торак бинаны торак булмаган бинага күчерүгә ризалыгы».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Алексеевск муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары А.Н.Абакумовка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К. Кадыйров**